ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында
гражданнар җыены карары нәтиҗәләре турында

25.10.2024 ел №1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгының 2024 елның 14 октябренддәге 11 номерлы "Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында үзара салым акчаларын кертү буенча гражданнар җыенын билгеләү хакында "2024 елның 6 апрелендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2024 елның 6 апрелендәге 6 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертү хакында" 2024 елның 25 октябрендә узган җыенда "2024 елның 6 апрелендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 6 апрелендәге 6 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертергә Сез ризамы" дигән сорау буенча беркетмә төзелде һәм чаралар түбәндәгечә бәян ителде:

«1) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (суга батыра торган су насосы сатып алу (2 данә), задвижка сатып алу (2 данә), Иске Гришкино торак пунктында су башнясын монтажлау, урнаштыру һәм тоташтыру).

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмәгә ярашлы: сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 381 кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны - 195 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«риза» - гражданнар җыенының 195 катнашучысы тавыш бирә;

«каршы» - 0

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены КАРАР КЫЛДЫ:

1. Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино авылында гражданнар җыены узган дип таныргa, гражданнар җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип таныргa.

2. "2024 елның 6 апрелендәге 5 номерлы «Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл җирлегенең Иске Гришкино торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында", 2023 елның 6 апрелендәге 6 номерлы " 2024 елда Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы Иске Гришкино авыл

җирлегенең  Иске Гришкино авылында  гражданнарның үзара салымнарын кертү турында" гражданнар җыеннары карарларына үзгәрешләр кертергә Сез ризамы” дигән  сорауны танырга һәм чараларны түбәндәгечә бәян итәргә:

«1) су белән тәэмин итү һәм су агызу системаларын, су җыю манараларын, скважиналарны һәм башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау, алар су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итү (суга батыра торган су насосы сатып алу (2 данә), задвижка сатып алу (2 данә), Иске Гришкино торак пунктында су башнясын монтажлау, урнаштыру һәм тоташтыру).

3. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә Иске Гришкино авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Менделеевск муниципаль районының рәсми сайтында (http://mendeleevsk.tatarstan.ru), Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында www.pravo.tatarstan.ru   бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Менделеевск муниципаль районы  Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгына  Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
ТР Менделеевск муниципаль районы
Иске Гришкино авыл җирлеге башлыгы ________ К.И.Алексеев

(имза) (имзаның аңлатмасы)